**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**30 октябрь 2018 ел** **№ 147**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турында нигезләмә хакында**

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кабул ителгән “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы”на, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставына, "Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында" нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 05 февралендәге 116 номерлы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы карарына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү үткәрү турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. "Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү турында нигезләмәне раслау хакында» Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советының 2008 елның 30 сентябрендәге 92 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Р.М. Нуруллин**

Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 октябрендәге 171 номерлы карарына кушымта

**Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында нигезләмә**

1. Әлеге типлаштырылган нигезләмә белән Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең (алга таба - җирле үзидарә органы) җирле үзидарә органнарында, җирлек сайлау комиссияләрендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә аттестация уздыруның гомуми тәртибе билгеләнә.

2. Аттестация муниципаль хезмәткәрнең биләгән вазыйфасына туры килүен билгеләү максатларында, аның һөнәри эшчәнлеген бәяләү нигезендә үткәрелә.

Аттестация муниципаль хезмәтнең кадрлар составын формалаштыруга, муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә, җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын кыскартуга өстенлекле хокукны билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы шартлары үзгәрүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән.

3. Түбәндәге муниципаль хезмәткәрләр аттестацияләнергә тиеш түгел:

1) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасында бер елдан ким эшләгән затлар;

2) 60 яшькә җиткән кешеләр;

3) йөкле хатын-кызлар;

4) йөклелек һәм бала табу буенча ялда яисә бала карау буенча ялда булган затлар - балаларына өч яшь тулганчы. Әлеге муниципаль хезмәткәрләрне ялдан чыкканнан соң бер елдан да иртәрәк аттестацияләү мөмкин түгел;

5) сроклы хезмәт килешүе (контракт) нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын башкаручы затлар.

4. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү өч елга бер тапкыр үткәрелә.

## 2 бүлек. АТТЕСТАЦИЯ ҮТКӘРҮНЕ ОЕШТЫРУ

5. Эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен җирле үзидарә органының, җирлек сайлау комиссиясенең түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алган хокукый акты чыгарыла:

1) аттестация комиссиясе төзү турында;

2) аттестация үткәрү графигын раслау турында;

3) аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләрнең

исемлекләрен төзү турында;

4) аттестация комиссиясе эше өчен кирәкле документларны әзерләү турында.

6. Аттестация комиссиясе җирле үзидарә органының, җирлекнең сайлау комиссиясенең хокукый акты белән төзелә. Күрсәтелгән акт белән аттестация комиссиясе составы, аның эш сроклары һәм тәртибе билгеләнә.

Аттестация комиссиясе составына эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле һәм (яки) моңа вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән бүлекчәдән, муниципаль хезмәт һәм кадрлар, юридик (хокукый) мәсьәләләр буенча бүлекчәдән, ә мондый бүлекчәләр булмаган очракта - муниципаль хезмәткәр аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органының кадрлар һәм юридик (хокукый) мәсьәләләр өчен җаваплы муниципаль хезмәткәрләре), шулай ук муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында персональ мәгълүматларын күрсәтмичә, фәнни, мәгариф һәм (яки) башка оешмалар вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар саны аттестация комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү өчен аттестация комиссиясе составы вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле рәвештә дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

Аттестация комиссиясе составы аттестация комиссиясе кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килү мөмкинлеген булдырмастай итеп формалаштырыла.

Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең биләгән вазыйфалары үзенчәлекләреннән чыгып, берничә аттестация комиссиясе төзелергә мөмкин.

7. Аттестация комиссиясе комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм әгъзалардан тора. Карарлар кабул иткәндә аттестация комиссиясенең барлык әгъзалары да тигез хокукларга ия.

8. Аттестация үткәрү графигы ел саен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан раслана һәм аттестация башланырга кимендә бер ай кала һәр муниципаль хезмәткәргә җиткерелә.

9. Аттестация үткәрү графигында түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) аттестация үткәрелә торган җирле үзидарә органы, бүлекчә исеме;

2) аттестацияләнергә тиешле муниципаль хезмәткәрләр исемлеге;

3) аттестация уздыруның датасы, вакыты һәм урыны;

4) аттестация комиссиясенә, тиешле җирле үзидарә органнарының, җирлек сайлау комиссиясе аппаратының тиешле бүлекчәләре җитәкчеләрен күрсәтеп, кирәкле документлар тапшыру датасы.

10. Аттестация башланганчы ике атнадан да соңга калмыйча

аттестация комиссиясенә аттестация чорында муниципаль хезмәткәрләргә аттестацияләнергә тиешле вазыйфаи бурычларның үтәлеше турында аның турыдан-туры җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм югарыдагы җитәкче тарафыннан расланган бәяләмә тапшырыла.

11. Әлеге типлаштырылган нигезләмәнең 10 пунктында каралган бәяләмәдә муниципаль хезмәткәр турында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

2) аттестация үткәрү вакытына биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы һәм шул вазыйфага билгеләнү датасы;

3) аны хәл итүдә муниципаль хезмәткәр катнашкан төп мәсьәләләрнең (документлар) исемлеге;

4) муниципаль хезмәткәрнең һөнәри, шәхси сыйфатлары һәм һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләре дәлилләнгән бәяләмә.

12. Аттестация чорында муниципаль хезмәткәрләргә аттестацияләнергә тиешле вазыйфаи бурычларны үтәү турында бәяләмәгә муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге турында еллык хисапларга кертелгән муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган йөкләмәләр һәм күрсәтелгән чор өчен аларга әзерләнгән документлар проектлары турында белешмәләр теркәлә.

Һәр аттестация узган саен аттестация комиссиясенә муниципаль хезмәткәрнең алдагы аттестация күрсәткечләре белән аттестация кәгазе тапшырыла.

13. Муниципаль хезмәт һәм җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе мәсьәләләре буенча бүлек аттестация башланганчы биш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә һәр аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрне аттестация чорында үзләренең вазыйфаи бурычларын үтәү турында тәкъдим ителгән бәяләмә белән таныштырырга тиеш. Шул ук вакытта аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр аттестация комиссиясенә күрсәтелгән чорда үзенең һөнәри эшчәнлеге турында өстәмә белешмәләр, шулай ук үзенең тәкъдим ителгән бәяләмә белән килешмәве турында гариза яисә турыдан-туры җитәкче бәяләмәсенә аңлатма язуы бирергә хокуклы.

## 3 бүлек. АТТЕСТАЦИЯНЕ ҮТКӘРҮ

14. Аттестация аттестация комиссиясе утырышына аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрне чакырып үткәрелә. Муниципаль хезмәткәр әлеге комиссия утырышына җитди сәбәпсез килмәгәндә яисә аттестацияләүдән баш тарткан очракта, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт турында законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла, ә аттестация соңрак вакытка күчерелә.

Аттестация комиссиясе тәкъдим ителгән документларны карый, аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрнең, ә кирәк очракта - аның турыдан-туры җитәкчесенең муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге турында фикерен тыңлый. Аттестацияне объектив үткәрү

максатыннан аттестация чорында аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәрләргә тапшырылган өстәмә мәгълүматларны караганнан соң аттестация комиссиясе аттестацияне комиссиянең киләсе утырышына күчерергә хокуклы.

15. Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм шәхси сыйфатлары турында фикер алышу объектив һәм дустанә булырга тиеш.

Муниципаль хезмәткәрнең һөнәри эшчәнлеге аның муниципаль хезмәт биләгән вазыйфасы буенча квалификация таләпләренә туры килүен билгеләү, бүлекчә (җирле үзидарә органы, җирлек сайлау комиссиясе аппараты) алдына куелган бурычларны хәл итүдә катнашуы, башкарган эшенең катлаулылыгы, аның нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгы нигезендә бәяләнә.

Шул ук вакытта муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкцияне үтәү нәтиҗәләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри белеме һәм эш тәҗрибәсе, муниципаль хезмәткәрнең чикләүләрне үтәве, тыюларны бозмавы, муниципаль хезмәт турында законнарда билгеләнгән йөкләмәләрнең һәм хезмәт тәртибе таләпләрен үтәве ә оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрне аттестацияләгәндә, шулай ук оештыру сәләте дә исәпкә алынырга тиеш.

16. Аттестация комиссиясе утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

17. Аттестация комиссиясе карары аттестацияләнүче муниципаль хезмәткәр һәм аның турыдан-туры җитәкчесе булмаганда, ачык тавыш бирү юлы белән аттестация комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда муниципаль хезмәткәр биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә дип танылa.

Аттестация комиссиясе әгъзасы булган муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү чорында аның әлеге комиссиядә әгъзалыгы туктатыла.

18. Муниципаль хезмәткәрне аттестацияләү нәтиҗәләре буенча аттестация комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә;

2) муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә;

3) өстәмә һөнәри белем алу шарты белән муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килә;

4) муниципаль хезмәт вазыйфасына туры килми.

19. Аттестация нәтиҗәләре аттестацияләнгән муниципаль хезмәткәрләргә тавыш бирү нәтиҗәләрен чыгарганнан соң ук хәбәр ителә.

Аттестация нәтиҗәләре кушымта нигезендә форма буенча төзелгән муниципаль хезмәткәрнең аттестация кәгазенә кертелә. Аттестация кәгазе утырышта катнашкан комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, секретаре һәм әгъзалар тарафыннан имзалана.

Муниципаль хезмәткәр аттестация кәгазе белән танышу турында кул куя.

Аттестация узган муниципаль хезмәткәрнең аттестация кәгазе һәм аттестация чорында аларның вазыйфаи бурычларын үтәү турында бәяләмәсе муниципаль хезмәткәрнең шәхси эше папкасында саклана.

Аттестация комиссиясе секретаре комиссия утырышы беркетмәсен алып бара, анда аның карарын һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен терки. Аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсенә утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм аттестация комиссиясе әгъзалары кул куя.

20. Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү материаллары эшкә алучы вәкиленә (эш бирүчегә) аны үткәргәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

21. Аттестация уздырганнан соң бер ай эчендә аның нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органының, җирлек сайлау комиссиясенең хокукый акты чыгарыла, яисә муниципаль хезмәткәрне эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан түбәндәгеләр турында карар кабул ителә:

1) вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына билгеләнгән тәртиптә кертелергә тиеш;

2) өстәмә һөнәри белем алу өчен җибәрелә;

3) түбәнрәк муниципаль хезмәт вазыйфасына күчерелә.

22. Муниципаль хезмәткәрнең квалификациясен күтәрүдән яисә муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерүдән баш тарткан очракта, яллаучы (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан һәм аны муниципаль хезмәт турындагы законнар нигезендә муниципаль хезмәттән азат итәргә хокуклы.

Аттестация уздырганнан соң бер ай узгач, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерү йә аны муниципаль хезмәттән әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча эштән азат итү рөхсәт ителми.

Муниципаль хезмәткәрнең авырган чоры һәм еллык түләүле ялы вакыты күрсәтелгән вакытта исәпкә алынмый.

23. Муниципаль хезмәткәр аттестация нәтиҗәләренә гамәлдәге законнар нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

Муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү үткәрү турында типлаштырылган нигезләмәгә кушымта.

# МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРНЕ АТТЕСТАЦИЯЛӘҮ КӘГАЗЕ

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ______________________________

2. Туган елы, көне һәм ае ______________________________

3. Һөнәри белеме, гыйльми дәрәҗәсе булу турында мәгълүмат ____________

______________________________

(кайчан һәм нинди уку йорты тәмамлаган, белгечлеге һәм квалификациясе

______________________________

белеме, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме буенча)

______________________________

4. Аттестация вакытына муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасы һәм бу вазыйфага билгеләнү датасы ______________________________

______________________________

5. Муниципаль хезмәт стажы (шул исәптән дәүләт гражданлык хезмәте стажы)______________________________

6. Гомуми хезмәт стажы______________________________

7. Муниципаль хезмәткәргә сораулар һәм аларга кыска җаваплар____________

______________________________

______________________________

______________________________

8. Аттестация комиссиясе тарафыннан әйтелгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр______________________________

______________________________

______________________________

9. Муниципаль хезмәткәрнең элекке аттестация тәкъдимнәрен үтәвен кыскача бәяләү ______________________________

______________________________

(үтәлгән, өлешчә үтәлгән, үтәлмәгән)

10. Аттестация комиссиясе карары ______________________________

(муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына

______________________________

муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә һәм вазыйфаи үсеш тәртибендә

______________________________

муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә

______________________________

кадрлар резервына кертүгә тәкъдим ителә; квалификацияне күтәрү шарты белән

______________________________

муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына туры килә; муниципаль хезмәт вазыйфасына

______________________________

турыкилми)

______________________________________________________________________
11. Аттестация комиссиясенең сан составы ______________________________
Утырышта аттестация комиссиясенең _________ әгъзасы катнашты.
_________ риза, __________ каршы тавышлар саны.
12. Искәрмәләр __________________________________________________________
______________________________________________________________________

Аттестация комиссиясе рәисе__________________ ___________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Аттестация комиссиясе рәисе урынбасары ________ _________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

Аттестация комиссиясе секретаре__________________ _____________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Аттестация комиссиясе әгъзалары_____________ ___________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)

__________________ _________________________________
(имза) (имзаның расшифровкасы)
Аттестация үткәрү датасы_____________________________________________
Аттестация кәгазе белән таныштым_____________________________________
(муниципаль хезмәткәрнең имзасы, дата)

Мөһер урыны
(җирле үзидарә органы, җирлекнең сайлау комиссиясе)